Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге составына керүче Бәйрәкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«12» ноябрь 2024 ел №1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 ноябрендә узган «Сез 2025 елда Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (тормыш иптәше, ата-аналары, балалары) тыш, 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы; әлеге түләүне бер тапкырга киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Бәйрәкә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчы белән техниканы арендалау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));
- Бәйрәкә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Абдуллин урамындагы юл-урам челтәрен (чокырларны ремонтлау) норматив хәлгә китерү);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, электр тарату пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, энергияне сак тота торган яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- халыкның күпләп ял итә торган урыннарын (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзекләндерү һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (материаллар, җайланмалар сатып алу, су агып яту урыннарын бетерү, торбаларны алыштыру, эш өчен килешү буенча түләү).

- Бәйрәкә торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар тоту, (зират территориясендә карт агачларны кисү, агачларны химик эшкәртү (химик препарат сатып алу), эш өчен килешү буенча түләү)) - соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 865 граждан кертелде;

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 467 кеше, бу 53,9% тәшкил итә.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Риза» позициясе өчен 467 граждан тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын узган һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында «Сез 2025 елда Бәйрәкә авыл жирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (тормыш иптәше, ата-аналары, балалары) тыш, 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы; әлеге түләүне бер тапкырга киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Бәйрәкә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчы белән техниканы арендалау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));

- Бәйрәкә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Абдуллин урамындагы юл-урам челтәрен (чокырларны ремонтлау) норматив хәлгә китерү);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, электр тарату пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, энергияне сак тота торган яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- халыкның күпләп ял итә торган урыннарын (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзекләндерү һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (материаллар, җайланмалар сатып алу, су агып яту урыннарын бетерү, торбаларны алыштыру, эш өчен килешү буенча түләү).

- Бәйрәкә торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар тоту, (зират территориясендә карт агачларны кисү, агачларны химик эшкәртү (химик препарат сатып алу), эш өчен килешү буенча түләү)) - соравы буенча гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина